| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2015 Казан ш. № 10-8/кс

***2015-2018 елларга «Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында***

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя куюу нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы карарына, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәлмәләрне исәплəп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2011 елның 15 февралендәге 47 санлы Россия Федерациясенең региональ үсеш министрлыгы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1.«Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча билгеләргә.

2.Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 июненнән 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына «Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.

4.«Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә ,билгеләнгән вакытка, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5.Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2014 елның 24 февралендәге 56 санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
1 нче кушымта
10.04.2015 № 10-8/кс

2015 – 2018 елларга, календарь чорларына бүлеп,
«Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе
тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы, муниципаль берәмлек атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 июненнән 2015 елның 30 июненә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 30 июненә кадәр | 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр | 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 июленнән 2017 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Әгерҗе муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» МУПы* | 85,03 | 87,49 | 87,49 | 90,43 | 90,43 | 94,44 | 94,44 | 99,30 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
10.04.2015 № 10-8/кс

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | 2015 елның 1 июненнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС тан тыш) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, мең куб.м., шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, мең куб.м., шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, мең куб.м., шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, мең куб.м., шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | |
| 1 | «Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе» МУПы* | 31,559 | 21,756 | 2,687 | 7,116 | 2722,29 | 31,559 | 21,756 | 2,687 | 7,116 | 2807,41 | 31,559 | 21,756 | 2,687 | 7,116 | 2917,08 | 31,559 | 21,756 | 2,687 | 7,116 | 3057,115 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге